**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
ӘҖМӘКӘЙ **АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ**

# КАРАР

«23» март 2021 г Яңа поселогы № 5

ӘҖМӘКӘЙ авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Конституциясе, «Оборона турында» 1996 елның 31 маендагы 61-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә мобилизация әзерлеге һәм мобилизацияләү турында» 1997 елның 26 февралендәге 31-ФЗ номерлы, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәне раслау хакында» 2006 елның 27 ноябрендәге 179 номерлы карары, «Хәрби исәпкә алу турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2020 елның 6 февралендәге 103 номерлы карары, «Тукай муниципаль районы ӘҖМӘКӘЙ авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә

## КАРАР БИРӘМ:

1. « ӘҖМӘКӘЙ авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәне раслау хакында» Башкарма комитетның 2020 елның 16 декабрендәге 12 номерлы карары белән расланган ӘҖМӘКӘЙ авыл җирлеге территориясендә беренчел хәрби исәпкә алуны оештыру һәм гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә һәм Запаста торучы гражданнарны хәрби исәпкә алу һәм броньлау буенча хезмәткәрнең вазыйфаи инструкциясенә үзгәрешләр кертергә:

1) Нигезләмәнең 3.8 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«3.8. Ел саен хәрби комиссариатка 1 октябрьгә кадәр – 15 яшькә җиткән ир-ат җенесендәге гражданнарның һәм 16 яшькә җиткән ир-ат җенесендәге гражданнарның исемлекләрен, ә 1 ноябрьгә кадәр киләсе елда беренчел исәпкә куелырга тиешле ир-ат җенесендәге гражданнар исемлеген тапшырырга.»;

2) Вазыйфаи инструкциянең 50 абзацын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Ел саен 1 февральгә кадәр хәрби комиссариатка алдагы елда беренчел хәрби исәпкә алу нәтиҗәләре турында хисап тапшырырга (Методик рекомендацияләргә 25 нче кушымта нигезендә).».

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны ӘҖМӘКӘЙ авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары Г.Ф. Гайнетдиновага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Р.Ф.Адиев